**СОВЕТ**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2022 елның «8» апреленнән                                                                                                   № 20-154

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 14-106 нчы номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җир кодексының 72 статьясына, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе субъектларында җәмәгать хакимиятен оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законнарга, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 14-106 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контроле турындагы нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 29 декабрендәге 17-132 номерлы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 статьяның 2.1 пунктын «мәҗбүри таләпләр» сүзләреннән соң «(2 нче кушымта)» тулыландырырга;
- кушымта нигезендә 2 нче кушымта белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы                                                                  В. М. Козлов

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Советының
2021елның 30 сентябрендәге 14-106
номерлы карары белән расланган
Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы территориясендә
муниципаль җир контроле турындагы
нигезләмәгә 2 нче кушымта

Муниципаль җир контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлеге

1. Контроль чара үткәрү нәтиҗәсендә билгеләнгән җир кишәрлегенең контрольдә тотылучы зат тарафыннан файдаланыла торган мәйданының җир кишәрлегенә хокук билгели торган күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрында булган җир кишәрлеге мәйданының туры килмәве.

2. Җир кишәрлеген контрольдә тотучы зат тарафыннан җир кишәрлегеннән файдалану максатыннан файдалану турында белешмәләр күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрында, җир кишәрлегенә хокук билгели торган документларда булган җир кишәрлегеннән фактта файдалануның туры килмәве.

3. Җир кишәрлеген бирү вакытыннан алып өч елдан артык вакыт узу яки җир кишәрлеген арендалау килешүендә күрсәтелгән җир кишәрлеген үзләштерү срогы тәмамлану, ә җир кишәрлегендә характерлы үзгәрешләр күзәтелмәү (капиталь төзелеш объекты булмау, төзелеш эшләре алып бару һәм җир кишәрлегеннән файдалану буенча башка гамәлләр һәм рөхсәт ителгән файдалану һәм бирү шартлары нигезендә башка гамәлләр булмау).

4. Җир кишәрлекләреннән файдалану өчен нигез булып торучы документларны рәсмиләштерүгә карата мәҗбүри таләпләрне үтәмәү.